ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2026 Мөслим № 44

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты нигезендә (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып),Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2026 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары белән,Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» 2024 елның 29 маендагы 190 номерлы карары белән,Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарга 1 нче, 2 нче һәм 3 нче кушымта нигезендә 9 678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2025 елның 31 гыйнварындагы 33 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар 2026 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И. Ф. Салихҗанов

ТР Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта ________ел №___

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе, авыл җирлекләрен дә кертеп, 2026 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә.

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, авыл җирлекләренең исеме | Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1 | «Әмәкәй авыл җирлеге» МБ | **9 678,63** |
| 2 | «Баланлы авыл җирлеге» МБ | |
| 3 | «Баек авыл җирлеге» МБ | |
| 4 | «Олы Чакмак авыл җирлеге» МБ | |
| 5 | «Вәрәшбаш авыл җирлеге» МБ | |
| 6 | «Исәнсеф авыл җирлеге» МБ | |
| 7 | «Крәш-Шуран авыл җирлеге» МБ | |
| 8 | «Мәлләтамак авыл җирлеге» МБ | |
| 9 | «Метрәй авыл җирлеге» МБ | |
| 10 | «Михайловка авыл җирлеге» МБ | |
| 11 | «Мөслим авыл җирлеге» МБ | |
| 12 | «Түбән Табын авыл җирлеге» МБ | |
| 13 | «Яңа Усы авыл җирлеге» МБ | |
| 14 | «Октябрь авыл җирлеге» МБ | |
| 15 | «Симәк авыл җирлеге» МБ | |
| 16 | «Иске Карамалы авыл җирлеге» МБ | |
| 17 | «Тойгелде авыл җирлеге» МБ | |
| 18 | «Үрәзмәт авыл җирлеге» МБ | |
| 19 | «Шуган авыл җирлеге» МБ | |

ТР Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
2 нче кушымта ________ел №___

2026 елның 01 февраленнән башлап, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны китереп бирү | 4 069,63 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1 360,55 |
| 4. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 4 248,45 |
| **Барлыгы** | 9 678,63 |

ТР Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
3 нче кушымта _______ ел № ___

2026 елның 01 февраленнән башлап, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
| --- | --- |
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Кәфенләү | 170,30 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны китереп бирү | 3 899,33 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1 360,55 |
| 5. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 4 248,45 |
| **Барлыгы** | **9 678,63** |